Балалар журналы

ISSN 0868-4545

Салават күпере



Илдә исә май җиле...



Исә җил – май җиле.
Илдә Май тантана итә.
Җирдә Май иртәсе – яз иртәсе.

Май җиле исә...

Талгын җил чәчләребезне, йөзләребезне, күңелләребезне иркәли, йөрәк түрендәге шигъри моң-аһәңнәрне ак кәгазь өстенә сибә...

Май җиле дәү бабайларыбызның хәтерләрен яңарта, алар Бөек Ватан сугышында күргән-кичкәннәрен янә бер кат күңелләре аша үткәрәләр, сугышчан дусларын сагынып, якты хатирәләргә биреләләр...

Май җиле – Хәтер җиле...

Дәү бабайларның күзләрендә – яшь тамчылары...

Дәү бабайлар нәсел-ыруларының дәвамчыларына – оныкларына карап, күз яшьләре аша елмаялар...

Бабайларның күзләрендә, телләрендә, күңелләрендә бер уй, бер теләк бүген: «Берүк сугыш булмасын иде! Берүк сугыш җиле исмәсен иде!..»

Илдә, шөкер, Май җиле исә...

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



© "Салават күпере", 2005 ел



«Без – Тукай шәкертләре»

Тукай якташлары

Горурланабыз туганга
Ямьле Арча җирендә.
Атаклы Казан артында,
Бөек Тукай илендә.

Тукай «Туган тел»ен җырлап,
Мәктәпләрдә укыйбыз.
Су анасы, шүрәле дә –
Безнең якын дустыбыз.

Тиккә генә зурламыйлар, –
Без бит Арча яклары.
Горурланып һич туймыйбыз:
Без – Тукай якташлары!

Рәмил ГӘРӘЕВ, 10 яшь. Арча, Сеҗе.



Казанга барабыз...

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап.
Шулвакыт безнең каршыга килеп чыкты бер бүре...
– Хәзер мин сезне ашыйм! – дип,
юлны бүлде бит теге.
Арба төбендә ята иде Кәҗә белән Сарык,
Шуларны күрсәткән идем, китте бит бүре чабып.
Төн иде, күктә йолдызлар җемелдәшеп ялтырый,
Куаклыкта мескен бүре куркуыннан калтырый.
Башкалага юл бик озын, төне буе барасы.
Янда Кәҗә, Сарык, Акбай – бар да Тукай «баласы».
Алар янымда булганда, кыскара озын юллар.
– Тиздән – Казан каласы! – дип, кычкыра Шүрәлеләр.
Тукай абый туган көнгә ат җигеп туры килдек:
– Дәртле, нурлы, моңлы Казан, каршы ал безне! –
дидек.
Һич безне куркытмадылар Шүрәле һәм дә бүре –
Тукайны күрү теләге яулады күңелебезне.

Илдар ШӘЕМОВ, 12 яшь.
Актаныш, Такталачык.

«Без – Тукай шәкертләре» бәйгесенә нәтиҗә ясадык – җиңүчеләрне ачыкладык. Журналның күләме кечкенә булу сәбәпле, бик күп яшь авторларыбызның язмалары, рәсемнәре, ни кызганыч, «Салават күпере» битләрендә дөнья күрү бәхетенә ирешә алмады. Бәйгедә катнашкан ул укучыларыбыз күңелләрен төшермәсен: без аларга да истәлекле бүләкләр җибәрәчәкбез. Бу санда без әлеге талантларыбызның исем-фамилияләрен телгә алып китәргә булдык. Менә алар:

Гүзәл ХАҖИЕВА *(Актаныш, Күҗәкә)*, Рәзинә ГАЗИЗУЛЛИНА *(Арча, Ташкичү)*, Гүзәл ЗӘЙНУЛЛИНА *(Апас, Әҗем)*, Рәмис КӘЛИМУЛЛИН *(Азнакай)*, Рамилә ГАРИФУЛЛИНА, Гөлия МӨХӘММӘТГАЛИЕВА, Рания НУРУЛЛИНА *(Саба, Сатыш)*, Заһидә КОРБАНГАЛИЕВА *(Кукмара, Зур Сәрдек)*, Зилия ШӘРӘПОВА *(Балык Бистәсе, Күгәрчен)*, Чулпан ӘСХӘТҖАНОВА *(Балтач, Куныр)*, Ранис ЗАКИРОВ *(Яшел Үзән, Татар Танае)*, Әлфия ХАФИЗОВА *(Балтач, Кили)*, Илүзә ГАЛӘҮЕТДИНОВА *(Азнакай)*, Язилә МИҢНЕМУЛЛИНА *(Кукмара, Купка)*, Камилә МУСИНА *(Буа)*, Илүзә ШАКИРОВА, Миләүшә ХАННАНОВА, Миләүшә ГАЙНЕТДИНОВА *(Мөслим, Метрәй)*, Венера ЮНЫСОВА *(Мамадыш, Уразбахты)*, Анастасия ИВАНОВА *(Мамадыш, Җөри)*, Гөлия ХӨСӘЕНОВА, Гүзәл ХӘБИБУЛЛИНА *(Арча, Мөндеш)*, Фазыл ХИСӘНБӘТОВ, Данис ГЫЙЛЬМЕГАЯНОВ *(Әгерҗе, Яңа Авыл)*, Ринат ХӘСӘНШИН *(Зәй, Сармаш-Баш)*, Алсу ЯЛАЛОВА *(Актаныш, Түбән Яхшый)*, Румия МУЛЛАХМӘТОВА *(Теләче, Олы Мишә)*, Гөлинә НӘҖИПОВА *(Балтач, Борнак)*, Ләйсән ЗАКИРОВА, Регина ШӘРИПОВА, Илфинә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА *(Мамадыш, Кече Кирмән)*, Энҗе ЧАРЫШЕВА *(Казан)*, Гомәр ҖӘЛӘЛЕТДИНОВ *(Чүпрәле, Иске Задур)*.

Иҗат дәвам итә... Сездән кызыклы, яңа язмалар, шигырь-әкиятләр көтеп калабыз.



Айзат ГАЗИЗОВ, 6 яшь. Азнакай.



Гөлинә ГАЙНУЛЛИНА. Саба районы, Сатыш.

Тәүфикъ ӘЙДИ

Очар малай

Бүлмәдә – җил. Ишектән керә дә, пәрдәләрне җилфер-җилфер селкетеп, тәрәзәдән чыга. Юл уңаенда Айнурның битләрен сыйпап: «Син егет кеше, курчак уйнаучы сеңелләреңне караулап өйдә генә ятма, әйдә бакчага чык, мин сине ястык болытка утыртып, күктә очыртып йөртермен», дип пышылдый.

Айнур әтисе шүрлек ясарга әзерләп куйган такталар өстендә аякларын тирбәтеп утыра. Аннары кулларын җәеп, кош канатыдай җилпи башлый. Һава су кебек куера, Айнур утырган җиреннән аерылып, өскә күтәрелә, ачык тәрәзә аша урамга чыгып китә. Аяклары, суда йөзгән шикелле уйнаклап, биеккә менеп җитәргә булыша.

– Мин очам! – дип кычкыра ул берзаман кызларга.

Алсу белән Әлфия күтәрелеп аңа карыйлар да шаккаталар: абыйлары, чыннан да, күктәге болыттай, һавада йөзә, кошныкы кебек канаты да, самолетныкы кебек пропеллеры да юк. Алсу, шундук уенчыкларын атып бәреп, кәҗәләнә башлый:

– Минем дә очасым килә!

– Ашыкма, нәнием. Башта мин әйбәтләп сынап карыйм әле.

– Юк инде, – ди Алсу, киреләнеп. – Йә икәү бергә очыйк, йә син дә җиргә төш!

– Бергә ярамый, – дип аңлата Айнур. – Элек үзем остарыйм әле, аннары сезне дә өйрәтермен.

– Әйем. Минем дә хәзер үк очасым килә.


– Егылып төшсәк?! – дип куркытмакчы була аны абыйсы.

– Булсын!

– Ярамый. Имгәнүең бар.

Айнур сеңелесенә бүтән колак салмый. Суда йөзгән шикелле, кушаягы белән һаваны ишә-ишә, биектә рәхәтләнә. Башта, егылып төшүдән шүрләп, артык югары күтәрелми, түтәлләр өстендә генә әйләнә. Аннары кыюлана барып, өй түбәсе югарылыгына менә. Аякларын селкетеп, бөтен гәүдәсе белән киерелүе була, сабан тургаедай өскә атыла. Икенче хәрәкәт ясап, алан өстеннән очып үтә. Дачаларга уздырылган электр чыбыгы да, телевизор антенналары да аста кала. Айнур, бераз иләшә төшкәч, тагын да өскәрәк күтәрелә, һава ерып барудан күкрәгенә әлегәчә

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



татылмаган рәхәтлек тула. Каен ябалдашлары югарыдан сизелер-сизелмәс кенә тирбәлгән яшел болыт кебек күренә. Кул сузымы җирдә җәелеп яткан күл көзгедәй ялтырый, урман артында исә биек ак ташпулатлар тезелешеп киткән. Алар яши торган кала ич бу. Нинди рәхәт, нинди күңелле икән бу очу. Мондый биеклектән тукраннар да, чын аю-бүреләр дә уч төбендәгедәй әллә кайдан күзгә чалына. Кош кебек өсләренә генә очып төшәсең дә башларыннан сыйпап үтәсең. Калага да очып кына кайтасың. Өйрәтәчәк, Алсу белән Әлфияне дә, һичшиксез, өйрәтәчәк ул очарга!

Чү! Алсулар бакчадан аңа кул болгыйлар түгелме соң? Әллә әти-әниләре кунактан кайтып җиткәнме? Тукта, һәммәсе хафаланмасын, тизрәк яннарына төшәргә кирәк!

Айнур аякларын кыймылдата да, канатларын җәйгән күгәрчен сыман, салмак кына түбәнәя башлый, һавада тирбәлә-тирбәлә, бал корты, төклетура сыман безелдәп, икенче каттагы тәрәзә аша өйгә очып керә. Әмма тизлеген вакытында киметә алмыйча, ниндидер каты нәрсәгә шапылдап килеп бәрелә...

Күзен ачса, ул чыннан да идәндә ята икән. Бүлмәдә ут яна, әти-әниләре радио тыңлый. Алсу ялгызы гына җилләткеч янында чәен суытып утыра. Абыйсының якягына аңлы-миңле каpануын күргәч, ул кулларын чәбәкли-чәбәкли:

– Егылды, йокы чүлмәге егылды! – дип кычкырды.

Айнур эндәшмәде. Аның яңадан күккә күтәреләсе, сеңелесен дә очарга өйрәтәсе килә иде.






Табашка

– Әй табашка, табашка!

Башын суза табашка
Минем таныш тавышка.

– Табашка да табашка...
Минем исемем башка –
Таш бака мин,
ТАШ БА-КА!



Рәшит БӘШӘР
шигырьләре

Кик-ри-күк

Әби әйтә: – Күкри күк!
Ә мин әйтәм: – Кик-ри-күк!

Абзарга качты әтәч:
– Кик-ри-күк! Күкри күк! Күк!

Хәтта әтәч тә кычкыра
Белә икән минем күк.



Кояшлы көн

Чиләкләремә салып
Ком апкайттым әнигә.
Миңа ияреп ишектән
Кояш та керде өйгә.


Әни, комны тигезләп,
Җәйде гөлләр төбенә.
Кояш йөри тәгәрәп,
Бүлмәләрдә гөл көлә.

Кояш куна гөлләргә,
Кояш куна әнигә.
Гөл дә матур!
Әни дә!

Ышанызгыз сүземә:
Бик-бик матур үзем дә!



Рәссам Диләрә НӘҮРҮЗОВА



Күбәләк

Канатымны сыйпый җил...

Җил тирбәлә,
Мин тирбәләм.

Хушбуй исе тирә-юнь...

Җир тирбәлә,
Мин тирбәләм.





Эльвина АГАДУЛЛИНА, 9 яшь.
Казан.



Ленар АГАДУЛЛИН, 5 яшь.
Казан.



Рәнис ШӘРИФУЛЛИН, 7 яшь.
Мамадыш, Дусай.



Милена ФАЗЛЫЕВА, 4 яшь.
Казан.



Илнар ХӘБИБРАХМАНОВ, 6 яшь.
Балтач, Яңа Салавыч.



Эльвира ИБРАҺИМОВА, 7 яшь.
Чистай, Уракчы.



Таңсылу ГОМӘРОВА, 12 яшь.
Чистай Уракчы.

Язның беренче чәчәге

Әкият

Бик борынгы заманнарда булган ди бу хәл. Табигать патшасы чәчәкләр арасында хәбәр тараткан:

– Озакламый яз җитә. Сезнең арагыздагы иң матур чәчәккә Җир өстендә яз тантана итүен хәбәр итү, кешеләрне беренче булып куандыру мөмкинлеге бирәчәкмен, – дигән.

Чәчәкләр арасында бәхәс купкан. Һәркайсы иң беренче булырга теләгән.

– Мин барыгыздан да матуррак. Мин язның беренче чәчәге булырга тиеш! – дигән Ромашка. – Минеке кебек ак таҗлар кайсыгызда бар соң?

Кыңгырау чәчәк аның белән килешмәгән:

– Мин бер чыңласам, бөтен дөнья ямьгә күмелә. Беренчелек миңа булырга тиеш! – дигән.

Бәхәскә башкалар да кушылган. Бер-берсен тыңлап та тормыйча, үзләрен мактаганнар.

Умырзая гына бер читтә басып торган, бәхәсләргә кушылмаган.

Табигать патшасы боларны тыңлап торган да болай дигән:

– Әйе, сез барыгыз да матурлар, кирәклеләр икәнсез! Ләкин тыйнаклык – ул үзе иң зур матурлык. Арагыздагы тыйнак Умырзаяны мин язның беренче чәчәге итеп билгелим.

Менә шул көннән бирле, җир өстендә карлар беткәнче үк Умырзая шытып чыга. Үзенең тыйнаклыгы һәм матурлыгы белән кешеләрне куандыра.

Айгөл МӨХӘММӘТШИНА, 9 яшь.
Арча, Иске Иябаш.

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ

Салават күпере

(Хикәя)


Авылга кайтып китәр алдыннан Саматка әнисе җиде карандаш сатып алды. «Көзен мәктәпкә барасың, кулың күнегә торсын!» – диде ул, улының такыр башыннан сөеп...

Карандашларның җидесе җиде төстә: яшел, зәңгәр, кызыл, сары, күк, шәмәхә һәм... Җиденчесен Самат «әфлисун карандаш» дип атады.

«Әфлисун карандаш» белән кояш ясавы рәхәт. Шуңа күрә дә әнисе алып биргән ак кәгазьгә Самат иң элек матур, нурлы кояш төшерде. Кояш янында күк була. Самат уйлап та куйды: «Күк төстә булганга күккә күк диделәр микән әллә?» Шул күктә зәңгәр болытлар йөзеп йөри... Тагын да астарак – яшел агачлар, яшел камышлар, үләннәр, сары чәчәкләр, кызыл җиләкләр, зәңгәр дулкынлы күл... Шунда ук сары иген басулары, ашлык сугып йөрүче кызыл комбайннар, бер читтәрәк – игеннәрдән бушап калган, инде сөрелеп куелган шәмәхә кырлар...

Менә кызык: дөньяның бөтен матурлыгы шушы җиде төскә керә дә бетә...

Самат аңлап алды: ул шушы җиде карандашы белән әбисе яшәгән авыл кырларын, андагы урманнарны, күлләрне төшерә икән бит! Ә авыл үзе кайда соң? Әнә ул – ак тәпиле сары эт белән яшел түбәле зәңгәр йорт. Самат ул таныш йорт янына яшел чыршы утыртты, кызык итеп кенә, зәңгәр чәчәк төшерелгән кызыл күлмәкле бер кыз рәсемен дә ясап куйды. Бу кыз әбисе күршесендә яшәүче Гөлсинә кебек үк чибәр булмаса да, аңа бик тә, бик тә охшаган иде...



Рәссам Алла АЙСИНА

Шулвакыт әнисенең тавышы ишетелде:
– Самат, улым, әйдә, без җыенып беттек, син әзерме?

... Авылдан Самат җылы, кояшлы яңгыр вакытында кайтты. Чыланса чыланды, әмма автовокзалдан өйләренә кайтканчы туган көненә әтисе бүләк иткән зонтигын чыгармады. Кызлар түгел лә ул... Аннары, әбисе дә гел әйтеп тора: «Яңгыр астында йөрсәң, тизрәк үсәсең», – ди. Ә Саматның бик тә, бик тә үсәсе килә. Гөлсинә өчен үсәсе килә. Быел җәй Самат аңа: «Син миңа ошыйсың», – дип әйткән иде, Гөлсинә: «Мондый сүзләрне үскәч сөйләшәләр», – дип кенә куйды.

Өйләрендә Саматны өстәлдә моңаеп яткан кәгазь бите каршы алды. Ап-ак кәгазь... Тукта-ле, кая киткән соң моның рәсемнәре? Самат бик яхшы хәтерли: матур рәсемнәр төшереп калдырган иде ул бу биткә. Әнисе бүләк иткән җиде карандаш белән төшергән иде...

Бу гаҗәеп хәлдән аптырап торган Самат, нидер сизенеп, тәрәзәгә күтәрелеп карады. Ярый карады әле! Чөнки тәрәзә артындагы гүзәллек аны бу кыен хәлдән йолып алды...

Тәрәзә артында, бөтен күк йөзе буйлап, җиде төсен дә бердәй балкытып, салават күпере көлеп тора иде!

Әһә! Менә кайда икән хикмәт! Өстәлдә калган кәгазьдәге бөтен төсләрне үзенә җыеп алган бит бу күк йөзе! Саматның рәсемнәрен ошаткан ул, ошаткан! Әфлисун кебек кояш, бер ай буе шушы рәсемнәргә карап торган-торган да, менә бүген генә, Саматның кайтасын белеп, аңа матур бүләк ясарга уйлаган!

Саматка рәхәт булып китте. Ул юл биштәреннән авылда чакта шактый кыскарып өлгергән җиде карандашын барып алды да, тәрәзәгә карый-карый, күк йөзендә һаман балкып, көлеп торган салават күперен төшерергә кереште...







Танылган шагыйрь һәм язучы Рафаил Газизовның 2003 елда «Мәгариф» нәшриятында басылган «Бүләгем» китабы өчен Г.К.Андерсен исемендәге Халыкара диплом белән бүләкләнүе хакында шушы көннәрдә Швейцариядән Татарстанга күңелле хәбәр килеп ирешде. Моңарчы бу олуг бүләккә балалар шигъриятенең күренекле әдипләре Шәүкәт Галиев белән Роберт Миңнуллин лаек булган иде.

Шагыйрь Рафаил абый ГАЗИЗОВны бу күркәм уңышы белән чын күңелдән котлыйбыз! Аңа яңадан-яңа иҗади уңышлар, саулык-сәламәтлек һәрдаим юлдаш булуын телибез!



Беләсезме...

Чәчәкләрне бергә тездем –
Бәйләм булды.
Әниемә, әбиемә
Бәйрәм булды.

Бәйләм-бәйләм гөлләр җыйдым –
Болын булды.
Кулларыма күбәләкләр
Килеп кунды.

Болыннарны бергә җыйдым, –
Таныдыгыз.
Каршыбызда: туып-үскән
Авылыбыз.

Рәссам Диләрә НӘҮРҮЗОВА

Фоторәсем... табышмак

«Салават күпере»ндә (№ 2, 2006) басылган «Фоторәсем... табышмак»ка укучыларыбыздан бик күп җаваплар килде. Хат-җавап җибәрүчеләрнең барысы да диярлек фотосурәттәге Әкиятче Бабай белән Әкиятче Абыйның кем икәнлекләрен дөрес әйткән:

Әкиятче Бабай – БАТУЛЛА,
Әкиятче Абый – Ләбиб ЛЕРОН.

Журналханәгә, иң беренчеләрдән булып, дөрес җавап юллаучылар – менә кемнәр:

Гөлнур һәм Назилә АРСЛАНОВАлар *(Мөслим, Урәзмәт)*
Азалия ФӘТТАХОВА *(Актаныш)*
Алсу ИСХАКОВА *(Мәскәү)*
Элмира ӘНӘСОВА *(Түбән Кама)*
Динар ИСМӘГЫЙЛОВ *(Саба, Бигәнәй)*
Рафис ХӘЛИМОВ *(Мөслим, Түбән Табын)*
Азат һәм Илмир АХУНОВЛАР *(Чаллы)*
Илиза СӘМӘРКАНОВА *(Азнакай, Уразай)*
Оля һәм Мария АНДРЕЕВАЛАР *(Кукмара, Пчеловод)*
Аяз САЛИХОВ *(Казан)*
Нәфисә ХӘСӘНОВА *(Арча)*
Алсу ГАРИФУЛЛИНА *(Азнакай)*
Гөлнара КАСЫЙМОВА *(Теләче, Алан)*
Минзилә СӘФӘРГАЛИЕВА *(Саба, Нырты)*



Әлеге укучылар мөхтәрәм язучыларыбыз Батулла һәм Ләбиб Леронның култамгалары (автографлары) куелган әкият китапларына ия булдылар. Котлыйбыз!

«Салават күпере» белән даими элемтәдә булып, хәбәрләшеп торулары өчен түбәндәге укучыларыбызга рәхмәт белдерәбез:

Роза Шакирҗанова (Арча, Яңа Кенәр), Алинә Гарифуллина (Түбән Кама, 2 нче татар гимназиясе), Рәсимә Мәгъсумова (Арча, Печмәнтау), Алсу Гәрәева (Әлмәт, Кичүчат), Нияз Гафиев (Кукмара, Люга), Зөлфирә Хисамова (Балтач, Чапшар), Рания Гыйниятуллина (Буа, Кайбыч), Фәрит Хөснетдинов (Әтнә, Бәрәскә), Лилия Абдуллина (Арча, Акчишмә), Айдар Миңнекәев (Әлмәт, Түбән Мактама), Илүзә Гарипова (Апас), Ләйсән Сабирҗанова (Әтнә, Ключи Сап), Глүсә Әскәрова (Балтач, Арбор), Гөлчәчәк Мөхәмметгалиева (Арча, Яңа Кенәр), Айсылу Салихова (Тукай, Биклән), Гөлфия Әхмәдиева (Балык Бистәсе, Ямаш), Эльмира Әкбәрова (Әлки, Иске Камка) Рузилә Фәттахова (Арча).

Уңышлар телибез сезгә. «Салават күпере» һәрвакыт юлдашыгыз булсын!

Игътибар! Күңелле хәбәр!

«Салават күпере» журналын икенче яртыеллыкка яздыручыларга КЫЗЫКЛЫ (!!!) бүләкләр киләчәк! Бу хакта дусларыгызга, танышбелешләрегезгә дә әйтергә онытмагыз!



Ләбиб ЛЕРОН


Рәхмәт


Су сипсә, Әхмәткә гөлләр рәхмәт әйтәчәк. Сөт эчерсә, аңа мәче дә рәхмәт әйтәчәк. Җим сипсә, кошлар да рәхмәт әйтәчәк Әхмәткә. Сөяк бирсә, маэмай да рәхмәт әйтәчәк. Алларына печән салса, ат та, сарык та, сыер да, кәҗә дә рәхмәт әйтәчәк аңа. Бәбкәләрен тилгәннән сакласа, казлар рәхмәт әйтәчәк. Булышса, кушкан йомышларын үтәсә, әтисе дә, әнисе дә, әбисе белән бабасы да, хәтта сеңелесе дә рәхмәт әйтәчәк Әхмәткә!

Шушы эшләрнең хет берсен генә эшләсә дә, мин дә әйтәчәкмен:

– Рәхмәт, Әхмәт! – диячәкмен.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ





Камилә,
2 яшь 6 ай

– Бигрәк тәмле бу йөзем!
Бигрәк өлгердер үзем:
Табындагы бар йөземне
Ашап куйдым берүзем!

Казан.




Зәринә, 1 яшь 3 ай

– Әллә чынлап, әллә юри
Күңелгә шом салдылар:
«Өйгә тычкан кергән!» – диеп,
Котларымны алдылар...

Казан.





Тимур, 1 яшь 2 ай
Руслан, 8 ай

– Такталарны өеп куйдык –
Арыдык тәмам.
Ашарга китерүче юк –
Көтәбез һаман!

Чүпрәле–Казан.



Рәфилә, 2 яшь 5 ай

– Өй эче зур – болын кебек,
Вилсәпидем – колын кебек.
Утырыйм да «колыныма»,
Чабыйм әле «болын» буйлап...

Кукмара, Березняк.

«Шүрәле»гә килгән хатлар



«Салават күпере» журналының март санында Вакыйф Нуриевның «Шүрәле» дип аталган хикәя-табышмагын бастырып чыгарган идек. Язучы аны Габдулла Тукай иҗатын күздә тотып язган. Хикәядә шагыйрьнең кайсы шигырьләре һәм әкиятләре чагылыш тапкан? Хикәя герое Самат аларның кайсын укыган, кайсын укымаган?

Сорауларның җавабы менә болай: Вакыйф абыегыз бу хикәя-табышмагын язганда Тукайның «Шүрәле», «Кәҗә белән Сарык» әкиятләренә, «Эш», «Ай һәм Кояш», «Сабыйга», «Эш беткәч уйнарга ярый», «Кызыклы шәкерт», «Эшкә өндәү», «Җир йокысы», «Гали белән Кәҗә» шигырьләренә таянган. Самат әкиятләрне генә укыган (әкият ярата икән).

Дөрес җавапларны беренчеләрдән булып Имил ГЫЙБАДУЛЛИН (Арча, Мөндеш), Ләйсән ФАРХАЕВА (Яңа Чишмә, Акъяр), Илмир ХӨРМӘЕВ (Мөслим, Тат.Бүләр), Айнур ЗИННӘТОВ (Балык Бистәсе, Ямаш), Айваз КАЮМОВ (Чүпрәле, Яңа Ишле) җибәрде. Зилә САБИТОВА (Арча, Шекә), Алия КЫЯМОВА (Тукай, Иске Абдул), Индира НӘГЫЙМОВА (Мөслим, Олы Чакмак), Илүзә НУРТДИНОВА (Чүпрәле), Зөһрә ЗАКИРОВА (Чистай), Гүзәл ЮСУПОВА (Тәтеш, Бакырчы), Рәнис ЗАКИРОВ (Яшел Үзән, Татар Танае), Динар ГЫЙЛЬФАНОВ (Кайбыч, Чүти), Люзия ӘХМӘТШИНА (Әлки, Бибай Чаллысы) һәм Мөслим районы Түбән Табын мәктәбенең беренче сыйныф укучылары редакциягә җибәргән җавапларында бер генә шигырьгә ялгышканнар. Дусларыбызның Тукай иҗатын яратулары безне сөендерде. Хәер, Тукайны ничек яратмыйсың инде?!

Без әкият иленнән!..

Ике малай бәхәсләшә.

– Мине ләкләк алып килгән! – ди берсе.

Икенчесенең дә сүзе әзер:

– Ә мине кәбестә арасыннан тапканнар!

Боларның сүзләрен өченчесе дә тыңлап торган икән. Ул бик җитди генә:


– Ә мин Әкият иленнән! – ди.

Ничек инде – Әкият иленнән?! Әкият илендә туганнарны без яхшы беләбез: Шүрәле малае, Су анасы, Камыр батыр... Ә син!? Син – Җир кешесе бит!

Өченче малайга әнә шулай дигәннәр. Ләкин аның җавабы әзер икән:

– Без, балалар, барыбыз да әкият яратабызмы? Яратабыз! Безнең һәммәбезнең дә әкияттәге Алып батырга охшыйсы киләме? Килә!

Беләсегез килсә, дөньядагы барлык балалар да Әкият иленнән була.



Әкият иле –Казандагы Груздев исемендәге клиника. (Элеккеге 3 нче номерлы бала тудыру йорты.)

Сәләват күпере

5(194) — 2006

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЖИР, МИЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ һӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.

1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РТ, ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.

Основан в 1990 году.

На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӘСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Диләрә НӘҮРҮЗОВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Л.ЗОЛОНДИНОВА рәсеме

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кечә яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: ck-sxn@newmail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиесе.

Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 4.05.2006 ел.
Басарга кул куелды 4.05.2006 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басылды.
Тираж 11463 данә. Заказ 3-346.

Санны әзерләүчеләр:
З.Хәснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Р. Зәйдулла, Н. Шаһиев, Н. Акмал, З.Вакказова, Г. Сабирова.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Ләбиб ЛЕРОН

Портрет

Портрет ясау җиңел түгел,
Ярый әле мин оста:
Җәнлек-җанварлар рәсемен
Ясадым бер минутта!

Буявын да тиз буядым,
Кулым бер дә армады...
...Үземне дә ясый идем –
Урын гына калмады.

